ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_____26.10.2020______ п.г.т.Алексеевское № _401___

**2021 елга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 12 декабрендәге 482 номерлы карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2021 елга кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар (Кушымта);

2. Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасында (Леденцов О.Н.) түбәндәгеләр раслаган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2021 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.В. Симашевага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Н.К. Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2020 елның 26 октябрендәге
401 номерлы карарына
кушымта

**Алексеевск муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 92 851 |
| | авыл җирлеге | 94 213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 139 227 |
| | авыл җирлеге | 143 701 |

**Башкарма комитет эшләре идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**